Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә 2024 елда гражданнарнын узара салымын керту турында гражданнар жыены карары нэтижәләре хакында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә яшәүче гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

22.11. 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлегенең яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, карамагында 18 яшькә кадәр балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан тыш, кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1. Скважинаны ремонтлау;
2. Суга батыру су насосын сатып алу (2 данә);
3. задвижкалар сатып алу (чугун 2 данә);
4. Скважина һәм фитинг (10 шт) өчен шланг сатып алу (20 м)
5. "Беларус МТЗ-82" тракторына техник хезмәт күрсәтү;
6. Иске Гришкино күпереннән соң озынлыгы 250 м; юл өчен вак таш сатып алу
7. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (үлән чабу);
8. Кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
9. Зиратта агачларны кисү
10. Карманково авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру;
11. Төньяк, Кояш урамнары буенча юл өчен вак таш сатып алу;
12. Юрашка елгасы аша Илкә авылы зиратына күпер салу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Иске Гришкино авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев